Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Иске Салман авыл Советы
КАРАРЫ.

2018 нче елның 8 нче ноябреннән 26 №

2018 елның 31 маенда кабул ителгән 9 номерлы "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарына сайланган депутатларның, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган оешмаларда эшләүче муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакындагы" Иске Салман авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында (Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 августындагы 17 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба-9 номерлы Карар)

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль хезмәткәрләр, хезмәткәрләр хезмәт өчен түләү шартларын тәртипкә салу максатларында, Әлки районы Иске Салман авыл җирлеге башкарма комитеты, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы "Депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы "Депутатлар җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затлары муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр" хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру" нормативларына үзгәрешләр кертү турында, Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 9 номерлы কарарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 9 номерлы карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советының 2009 елның 10 сентябрь 103 номерлы "Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл

җирлеге җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында" карарын, Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советының 2011 елның 21 маендагы 30 номерлы "Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында" карарын, 2009 елның 10 сентябрендәге 103 номерлы "Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

- 9 номерлы карарның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.»

- "Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында" Нигезләмәнең 2 нче өлешнең 2.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3 Авыл җирлеге башлыгы һәм аның урынбасарларына айлык акчалата бүләк түләү башлык өчен елына 6,72 айлык акчалата бүләк, аларның урынбасарлары өчен елына 8 айлык акчалата бүләк тәшкил итүче нормативтан артып китә алмый.»

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Иске Салман авыл Советы Рәисе,
авыл җирлеге башлыгы Җәләлетдинов Ф.И